КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 16 май г.Казань № 444

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 17 февраль, 92 нче; 2014 ел, 31 май, 371 нче; 2014 ел, 5 сентябрь, 643 нче; 2014 ел, 1 декабрь, 936 нчы; 2015 ел, 26 март, 186 нчы; 2015 ел, 28 август, 626 нчы; 2015 ел, 25 сентябрь, 710 нчы; 2015 ел, 29 декабрь, 1000 нче; 2016 ел, 24 март, 160 нчы; 2016 ел, 13 август, 554 нче; 2016 ел, 6 декабрь, 898 нче; 2017 ел, 13 март, 134 нче; 2017 ел, 13 июль, 479 нчы; 2017 ел, 8 сентябрь, 640 нчы; 2017 ел, 7 декабрь, 943 нче; 2018 ел, 24 гыйнвар, 35 нче; 2018 ел, 26 февраль, 107 нче; 2018 ел, 12 апрель, 235 нче; 2018 ел, 3 июль, 540 нчы; 2018 ел, 13 сентябрь, 775 нче; 2018 ел, 23 ноябрь, 1042 нче; 2019 ел, 26 гыйнвар, 43 нче; 2019 ел, 4 февраль, 66 нчы; 2019 ел, 28 февраль, 141 нче; 2019 ел, 30 апрель, 366 нчы; 2019 ел, 11 сентябрь, 816 нчы; 2019 ел, 10 декабрь, 1132 нче; 2020 ел, 7 февраль, 80 нче; 2020 ел, 25 май, 421 нче; 2020 ел, 24 июль, 621 нче; 2020 ел, 26 октябрь, 956 нчы; 2020 ел, 30 декабрь, 1229 нчы; 2021 ел, 21 май, 353 нче; 2021 ел, 19 июль, 586 нчы; 2021 ел, 6 ноябрь, 1055 нче; 2022 ел, 27 гыйнвар, 62 нче; 2022 ел, 15 март, 238 нче; 2022 ел, 22 март, 254 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы

халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программаның III бүлегендәге беренче абзацында «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау турында» 1997 елның 10 декабрендәге 1417 номерлы Татарстан Республикасы Законы,» сүзләрен төшереп калдырырга;

Программага 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«Халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү чараларын тормышка ашыру һәм хезмәт миграциясен җайга салу. Эшкә урнашканда яшь инвалидларга даими булышлык күрсәтеп тору» ярдәмче программасында (алга таба – Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасы):

Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасының I бүлегенә түбәндәге эчтәлекле бүлекчә өстәргә:

«Яшьләрне эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү

Татарстан Республикасында 15 – 29 яшьтәге якынча 600 мең яшь кеше яши, ягъни барлык халыкның 15 проценты.

2021 елда республиканың эш белән тәэмин ителгән халкы саны (беренчел мәгълүматлар буенча) 1 978 мең кеше тәшкил итте, 2020 ел белән чагыштырганда (1 953 мең кеше) үсеш 25 мең кеше тәшкил итте. Шул ук вакытта, 2020 ел белән чагыштырганда, 20 дән 29 яшькә кадәрге эш белән тәэмин ителгән кешеләр саны 22 мең кешегә кимеде (2020 елда 379 мең кешедән 2021 елда 357 мең кешегә кадәр). Нигездә, бу XX гасырның 90 нчы елларында илдә туучылар саны кимү факторы. Моннан чыгып, 2010 еллар башыннан Россиядә 20 – 29 яшьлек гражданнар төркеменнән чыга башлаган яшь хезмәткәрләр саны кимү тенденциясе күзәтелә.

Татарстан Республикасында 2010 елдан 2021 елга кадәр эш белән тәэмин ителгән яшьләр саны 118,1 мең кешегә кимегән (2020 елда 488,1 мең кешедән 2021 елда 370 мең кешегә).

Яшьләр – хезмәт ресурсларының иң динамик өлеше. Әлеге яшь категориясе югары мобильлеккә, тиз белем алуга потенциаль сәләткә, стандарт булмаган фикерләүгә ия. Бер үк вакытта яшьләр иң зәгыйфь төркемнәрнең берсе булып тора, бу хезмәт базарында конкуренциягә сәләтнең шактый түбән дәрәҗәсенә бәйле.

Яшьләрнең үсешендә төп мәсьәләләрнең берсе булып аларның эшкә урнашу мәсьәләсе тора.

Халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән эшсезләр составындагы яшьләр өлеше аз гына 13 проценттан артык тәшкил итә. Яшьләрне эшкә урнаштыруның төп проблемаларына түбәндәгеләрне кертергә мөмкин:

яшьләрнең уку белән эшне бергә алып баруы өчен мөмкинлекләр чикле санда булу, бу 20 – 24 яшьтәге төркемдә яшьләрнең эш белән тәэмин ителеше югары дәрәҗәдә булмауга китерә;

15 яшьтән 24 яшькә кадәрге яшьләрнең хезмәт өлкәсендәге мөнәсәбәтләргә тиешле рәсмиләштерелмәгән рәвештә җәлеп ителү дәрәҗәсе, эксперт бәяләре буенча, чагыштырмача югары булу;

яшьләр арасында һөнәри белеме яки әзерлеге булмаган эшсез затлар категориясе булу;

квалификацияле хезмәтнең конкурентлыкка сәләте түбән булу;

эш бирүчеләр ягыннан яшьләрнең эшче көчләре сыйфатыннан канәгать булмау;

хезмәт базарына чыкканда яшьләрнең бер өлешенең эш тәҗрибәсе булмау һ.б.

Хәл итүне таләп итә торган төп бурычлар:

яшьләрнең карьера стратегияләрен шәхси-һөнәри сәләтләре һәм хезмәт базары ихтыяҗлары нигезендә булдыру, шул исәптән һөнәри юнәлеш бирү буенча чаралар формалаштыру, һөнәрләр һәм предприятиеләр белән танышу максатында сәнәгать туризмын үстерү;

яшьләр тарафыннан алына торган белемнең эш бирүчеләрдәге һөнәри-квалификация таләпләренә туры килүен тәэмин итү, шул исәптән белем бирү оешмаларына кабул итүнең контроль саннарын формалаштыру һәм бүлү системасын камилләштерү һәм аларны хезмәт базары ихтыяҗларына якынайту;

белем алуны һәм хезмәт (эшмәкәрлек) эшчәнлеген бергә алып бару аша яшьләрнең һөнәри үсеше өчен шартлар тудыру;

яшьләрнең эш белән тәэмин ителмәү рискларын киметүнең өстәмә механизмнарын булдыру (һөнәри укыту чаралары, эшкә урнашуны субсидияләү (шул исәптән инвалидлыгы булган һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән затларны), яшьләр булышлык күрсәтеп торуны оештыру, шулай ук халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары тарафыннан эшкә урнаштыру (эш белән тәэмин итү) максатларында яшьләрнең аерым категорияләренә адреслы булышлык күрсәтүне тәэмин итү).

Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасына 4 нче кушымтада китерелгән, Яшьләрне эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү чаралары планында каралган чараларны тормышка ашыру түбәндәге күрсәткечләргә ирешергә ярдәм итәчәк:

2022 елда 15 яшьтән 29 яшькә кадәрге яшьләрнең эшсезлек дәрәҗәсе – 7,6 процент, 2023 елда – 7,2 процент, 2024 елда – 7 процент;

2022 елда 15 яшьтән 24 яшькә кадәрге яшьләрнең эшсезлек дәрәҗәсе – 14 процент, 2023 елда – 12,5 процент, 2024 елда – 11 процент.»;

Халыкны эш белән тәэмин итү ярдәмче программасына 4 нче кушымта (карарга теркәлә) өстәргә;

«Татарстан Республикасында хезмәт шартларын һәм аны саклауны яхшырту» ярдәмче программасының I бүлегендәге икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хезмәтне саклау белән идарә итү системасында Хезмәтне саклау буенча республика ведомствоара комиссиясенә (алга таба – РВК) аерым роль бирелгән. РВК бурычлары, вәкаләтләре һәм составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хезмәтне саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру турында» 2008 ел, 10 ноябрь 799 нчы карарында билгеләнде. Комиссия составына Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы территориаль органы, Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге, Татарстан Республикасы Һөнәр берлекләре федерациясе, дәүләт күзәтчелеге һәм контроле федераль органнары вәкилләре, шулай ук республика сәнәгать предприятиеләре вәкилләре керә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                                    А.В.Песошин

«2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә ярдәм күрсәтү» дәүләт программасына 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 16 май, 444 нче карары редакциясендә)

## «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә ярдәм күрсәтү» дәүләт программасы максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

| Максат исеме | Бурыч исеме | Ярдәмче программаның исеме | Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге | Еллар буенча индикаторлар мәгънәләре | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2021 ел (база) | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
| Гражданнарның тулы, продуктив эш белән тәэмин ителешенә хокукларын тормышка ашыруга булышлык | Халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт сәясәтен тормышка ашыруны тәэмин итү, Татарстан Респуб- | Халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү чараларын тормышка ашыру һәм хезмәт миграциясен | Уртача бер елга гомуми эшсезлек дәрәҗәсе (Халыкара хезмәт оешмасы методологиясе буенча), процент | 4,1 | 3,9 | 4,0 | 3,8 | 3,5 | 3,6 | 3,6 | 3,8 | 3,65 | 4,5 | 3,3 | 3,3 | 3,3 |
| | | | Ел ахырына теркәлә торган эшсезлек дәрәҗәсе, процент | 1,1 | 0,74 | 0,8 | 0,7 | 0,6 | 0,7 | 0,7 | 2,3 | 1,2 | 4,6 | 0,6 | 0,6 | 0,6 |
| | | | Бер елга уртача теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе, процент | | | | | | | | | | 3,2 | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| күрсәтү, шулай ук Татарстан Республикасы икътисадын кадрлар белән тәэмин итү | ликасы икътисады өчен кадрлар потенциалын үстерү | җайга салу. Эшкә урнашканда яшь инвалидларга булышлык күрсәтеп тору | Ел ахырына хезмәт базарындагы киеренкелек коэффициенты, кеше/вакансия | 1,7 | 0,4 | 0,7 | 0,6 | 0,34 | 0,5 | 0,5 | 1,65 | 0,7 | 2,1 | 0,4 | 0,4 | 0,4 |
| | | | һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларның гомуми санында уку тәмамланганнан соң беренче елда эшкә урнашкан әлеге оешмаларны тәмамлаучылар өлеше, процент | | | | 52 | 62,3 | 67,5 | 68 | 53,0 | 78 | 78,5 | 79,0 | 82,0 | 82,0 |
| | | | югары белем бирү мәгариф оешмаларын тәмамлаучыларның гомуми санында уку тәмамланганнан соң беренче елда эшкә урнашкан әлеге оешмаларны тәмамлаучылар өлеше, процент | | | | 75,0 | 64,5 | 56,7 | 56,7 | 65,0 | 65,0 | 65,0 | 65,0 | 65,0 | 65,0 |
| | Татарстан Республикасы территория- | Татарстан Республикасында хезмәт | Производствода 1 000 эшчегә исәпләгәндә зыян күрүчеләр саны, кеше | 1,17 | 1,00 | 1,24 | 0,69 | 1,2 | 0,94 | 0,85 | 0,83 | 0,81 | 0,79 | 0,77 | 0,75 | 0,75 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | сендә урнашкан оешмалар хезмәткәрләренең һөнәри куркынычларын киметү максатларында хезмәт шартларын һәм аны саклауны яхшырту | шартларын һәм аны саклауны яхшырту | | | | | | | | | | | | | | |
| | Татарстан Республикасы предприятиеләрендә эшчеләр һөнәрләре һәм инженерлык белгечлекләре кадрларын | Татарстан Республикасында эшчеләр һәм инженерлар һөнәрләрен популярлаштыру | Эшсез граждан-нар составында 16 – 29 яшьлек яшьләр өлеше, 16 процент | 25 | 22 | 20 | 18,0 | 16 | 20 | 19,5 | 30 | 18,5 | 18 | 17,5 | 17 | 16 |
| | | | Федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән белем алган һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары | 3,5 | 3,2 | 2,9 | 1,0 | 1,1 | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 2,0 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | җәлеп итү һәм беркетү | | белем бирү мәгариф оешмаларын тәмамлаучыларның эшсезләр составындагы өлеше, 2 процент | | | | | | | | | | | | | |
| | | | Һөнәри белем бирү оешмаларына һәм югары белем бирелә торган мәгариф оешмаларына укырга кергән студентларның гомуми санында федераль бюджетның һәм Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән уку өчен әлеге белем бирү оешмаларына техник белгечлекләр буенча укрыга кергән студентлар өлеше, процент | 46 | 47 | 48 | 52,0 | 62,3 | 50 | 50 | 50 | - | - | - | - | - |

«Халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү чараларын тормышка ашыру һәм хезмәт миграциясен җайга салу. Эшкә урнашканда яшь инвалидларга булышлык күрсәтеп тору» ярдәмче программасына
4 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 16 май, 444 нче
карары редакциясендә)

Яшьләрне эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү чаралары планы

| Т/с | Чараның исеме | Чараны тормышка ашыру срогы | Җаваплы башкаручы | Документның көтелә торган нәтиҗәсе/төре | Индикатор исеме | Индикатор мәгънәсе |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| Яшьләрнең карьера стратегияләрен формалаштыру | | | | | | |
| 1. | Эшләүче яшьләрнең «Сүз белән түгел, эш белән!» республика форумын үткәрү | ел саен | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы (алга таба – ТР ЯЭМ) | билгеләнгән күрсәткечләргә ирешү | чарада катнашучылар саны, кеше | 500 |
| 2. | Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы учреждениеләре органнары тарафыннан индивидуаль профилактик эш алып барыла торган, укымый һәм эшләми торган балигъ булмаганнарны эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтү | ел саен | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – ТР МһФМ), Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – ТР Хезмәт министрлыгы), Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре (алга таба – ТР | күрсәтелгән күрсәткечләргә ирешү | мөрәҗәгать итүчеләр саныннан эшкә урнаштырылганнар өлеше, процент | 80 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | ХЭбТИХ) | | | |
| 3. | Һөнәр сайлау һәм карьера төзү максатларында яшьләргә һөнәри юнәлеш бирү чараларын оештыру | ел саен | ТР Хезмәт министрлыгы, ТР МһФМ | чаралар оештырылды | чараларда катнашучылар саны, кеше | кимендә 40 000 |
| 4. | Һөнәри консультация бирү, һөнәри планнарны һәм ниятләрне ачыклау, җитешмәгән компетенцияләрне һәм квалификацияләрне ачыклау, индивидуаль-психологик үзенчәлекләрне бәяләү | ел саен | ТР МһФМ, Татарстан Республикасының һөнәри белем бирү оешмалары (алга таба – ҺББО) | һөнәри консультация бирү оештырылды | чарада катнашучылар саны, кеше | 80 |
| 5. | Татарстан Республикасы территориясендә округ һәм бөтенроссия хезмәт проектларын оештыру | ел саен | ТР ЯЭМ | проектлар оештырылды | чарада катнашучылар саны, кеше | кимендә 100 |
| 6. | Мәктәп укучылары өчен таләп ителә торган һөнәрләр буенча һөнәри әзерлек нигезләрен һәм һөнәри ориентацияне үз эченә алган «Һөнәргә кереш» комплекслы хезмәте күрсәтү | ел саен | ТР Хезмәт министрлыгы, ТР ХЭбТИХ ДУ | хезмәтләр күрсәтелде | «Һөнәргә кереш» комплекслы хезмәте күрсәтелү өчен мөрәҗәгать иткән мәктәп укучылары санына карата әлеге хезмәт күрсәтелгән мәктәп укучылары өлеше, процент | 100 |
| Алына торган белемнең эш бирүчеләрдәге һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендәге һөнәри-квалификация таләпләренә туры килүен тәэмин итү | | | | | | |
| 7. | Урта һөнәри белем бирү һөнәрләре һәм белгечлекләре исемлеген (ТОП-РЕГИОН) актуальләштерү | 2022 ел | ТР МһФМ | исемлек | исемлекләр саны, берәмлек | 1 |
| 8. | Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбен- | ел саен | ТР Хезмәт министрлыгы | дәүләт аккредитациясе булган мәгариф оешмалары арасында Татарстан Республикасы бюджеты | беркетмәләр саны, берәмлек | 1 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | нән урта һөнәри һәм югары белем бирә торган мәгариф программалары буенча укыту өчен гражданнар кабул итүнең контроль цифрларын бүлүгә конкурс үткәрүне оештыру | | | акчасы исәбеннән урта һөнәри һәм югары белем бирә торган мәгариф программалары буенча укыту өчен гражданнар кабул итүнең һөнәрләр, белгечлекләр һәм әзерлек юнәлешләре буенча контроль цифрларын бүлүгә конкурс үткәрү комиссиясе утырышы беркетмәсе | | |
| 9. | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән урта һөнәри белем бирү һөнәрләре, белгечлекләре буенча укытуга кабул итүнең контроль саннарын раслау | ел саен | ТР МһФМ, ТР Мәдәният министрлыгы; Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы | министрлыкларның боерыклары | боерыклар саны, берәмлек | 6 |
| 10. | Производство практикасын узуны оештыру (шул исәптән «Работа в России» халыкны эш белән | 30.12.2022, алга таба – ел саен | ҺББО, ТР ХЭбТИХ ДУ | билгеләнгән күрсәткечләргә ирешү | чыгарылыш укучыларның гомуми санында производство | кимендә 70 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | тәэмин итү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә бердәм цифрлы платформаны файдаланып) | | | | практикасын узган ҺББОның чыгарылыш курсларын тәмамлаучылар өлеше, процент | |
| 11. | Үзмәшгульлек формасында эшмәкәрлек эшчәнлеге алып бару үзенчәлекләре турында мәгълүмат бирү | ел саен | ТР МһФМ, ҺББО | билгеләнгән күрсәткечләргә ирешү | чараларда катнашучыларның гомуми санында үзмәшгульлек формасында эшмәкәрлек эшчәнлеге алып бару үзенчәлекләре турында мәгълүмат бирелгән тәмамлаучылар өлеше, процент | 100 |
| Белем алуны һәм хезмәт (эшмәкәрлек) эшчәнлеген бергә алып бару аша яшьләрнең һөнәри үсеше өчен шартлар тудыру | | | | | | |
| 12. | Эшкә урнаштыру мөмкинлекләрен арттыру максатларында волонтерлык эшчәнлеген үстерү чараларын тормышка ашыру | ел саен | ТР ЯЭМ | күрсәтелгән күрсәткечләргә ирешү | чарада катнашучылар саны, кеше | кимендә 500 |
| 13. | Эшсез гражданнарга эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлауда булышлык күрсәтү | ел саен | ТР Хезмәт министрлыгы, ТР ХЭбТИХ ДУ | күрсәтелгән күрсәткечләргә ирешү | үз эшен ачкан гражданнар саны, кеше | кимендә 380 |
| 14. | Студентларның хезмәт отрядлары составында яшьләрне эшкә урнаштыру | ел саен | ТР ЯЭМ | күрсәтелгән күрсәткечләргә ирешү | чарада катнашучылар саны, мең кеше | кимендә 11,5 |
| 15. | Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм мәгариф оешмалары буенча «Work-тур 2.0.» республика проекты | ел саен | ТР ЯЭМ | күрсәтелгән күрсәткечләргә ирешү | чарада катнашучылар саны, мең кеше | кимендә 3 |
| 16. | Һөнәри осталык буенча «Труд-Крут!» | ел саен | ТР ЯЭМ | конкурслар үткәрелде | конкурслар саны, | 2 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | республика кон-курслары | | | | берәмлек | |
| Яшьләрнең эш белән тәэмин ителмәү рискларын киметүнең өстәмә механизмнарын булдыру | | | | | | |
| 17. | Һөнәри белем бирү оешмасы каршында эшкә урнашуга бу-лышлык күрсәтү хез-мәтләрен булдыру | 2022 ел | ТР МһФМ, ҺББО | күрсәтелгән күрсәткеч-ләргә ирешү | ҺББО кар-шында эшкә урнашуга булышлык күрсәтү хез-мәтләрен булдыру, процент | 100 |
| 18. | Белем алучылар һәм чыгарылыш укучылар өчен вакансияләр яр-минкәләрен оештыру һәм уздыру | ел саен | ТР Цифра министрлыгы, ТР Хезмәт министрлыгы | вакансияләр ярминкәләре оештырылды | белем алу-чылар санына карата вакан-сияләр ярмин-кәсендә бул-ган белем алучылар саны, процент | кимендә 90 |
| 19. | Авыл хуҗалыгы һәм машина төзү тармак-ларында максатчан укыту практикасын киңәйтү | 2022 елның сентябре | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, ТР МһФМ | күрсәтелгән күрсәткеч-ләргә ирешү | максатчан уку турында төзелгән шартнамәләр саны, берәмлек | кимендә 50 |
| 20. | Студентларның хез-мәт отрядлары җитәк-челәре өчен белем бирү чаралары – мәктәпләр, стратегик сессияләр һ.б. | ел саен | ТР ЯЭМ | күрсәтелгән күрсәткеч-ләргә ирешү | чарада кат-нашучылар саны, кеше | кимендә 150 |
| 21. | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Де-мография» илкүләм проектының «Ха-лыкны эш белән тәэмин итүгә булыш-лык күрсәтү» феде-раль проекты кысала-рында аерым кате-гориядәге граждан-нарны һөнәри укы-туны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру чараларын тормышка | 2022 – 2024 еллар | ТР Хезмәт министрлыгы, ТР ХЭбТИХ ДУ | күрсәтелгән күрсәткеч-ләргә ирешү | белем алган 35 яшькә ка-дәрге яшьләр саны, кеше | кимендә 750, ел саен |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | ашыру өчен коммерциягә карамаган оешмаларга федераль бюджеттан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү турында» 2021 елның 13 мартындагы 369 номерлы карары нигезендә 35 яшькә кадәрге яшьләрнең аерым категорияләрен һөнәри укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирү | | | | | |
| 22. | Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре һәм мәгариф оешмалары арасында хезмәттәшлек итү һәм бергәләп эшләү турында килешүләр кысаларында һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларны эш белән тәэмин итүгә превентив булышлык күрсәтүне оештыру | ел саен | ТР Хезмәт министрлыгы, ТР МһФМ, ТР ХЭбТИХ ДУ, мәгариф оешмалары | күрсәтелгән күрсәткечләргә ирешү | эшсезләр составында һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирү оешмаларын тәмамлаучылар өлеше, процент | 0,2 |
| 23. | Урта һөнәри белем бирү программалары буенча укуны тәмамлаган чыгарылыш укучыларның эш белән тәэмин ителешен мониторинглау | ел саен | ТР МһФМ, ҺББО | аналитик мәгълүмат | мәгълүмат саны, берәмлек | 1 |
| 24. | Һөнәри белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларга хезмәт базары торышы турында, шул исәптән вакансияләр ярминкәләрен үткәрү турында мәгълүмат бирү | ел саен 1 мартка кадәр | ТР МһФМ, ҺББО | күрсәтелгән күрсәткечләргә ирешү | чыгарылыш укучыларның гомуми санында хезмәт базары торышы турында мәгълүмат бирелгән чыгарылыш укучылар өлеше, процент | 100 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 25. | Урта һөнәри белемле яки югары белемле һәм белем алу турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан ел дәвамында эш эзләүче 18 яшьтән 25 яшькә кадәрге эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру | ел саен | ТР Хезмәт министрлыгы, ТР ХЭбТИХ ДУ | күрсәтелгән күрсәткечләргә ирешү | эшкә урнаштырылган кешеләр саны, кеше | кимендә 55, ел саен |
| 26. | Тормыш хәлләре кысаларында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары тарафыннан яшьләрнең аерым категорияләрен эшкә урнаштыру (эш белән тәэмин итү) максатларында адреслы булышлык күрсәтеп торуны тәэмин итү | 30.12.2022, алга таба – ел саен | ТР ХЭбТИХ ДУ | хезмәтләр күрсәтелде | тормыш шартлары кысаларында хезмәт күрсәтелгән гражданнар саны, кеше | кимендә 50 |
| 27. | 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнар өчен (шул исәптән вакытлыча эшкә урнаштыру кысаларында) һөнәрне сынап карауны оештыру | 2022 ел,<br>2023 ел,<br>2024 ел | ТР Хезмәт министрлыгы, ТР ХЭбТИХ ДУ | күрсәтелгән күрсәткечләргә ирешү | 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарның гомуми санынннан һөнәрне сынап карауны (шул исәптән вакытлыча эшкә урнаштыру кысаларында) узган әлеге яшьтәге балигъ булмаган гражданнар өлеше, процент | 10,0<br>12,5<br>15,0 |
| 28. | Яшьләрнең аерым категорияләрен эшкә урнаштыруны субсидияләү чараларын оештыру,<br>шул исәптән:<br><br>эш бирүчеләргә яшьләрне эшкә урнаш- | 2022 ел | ТР Хезмәт министрлыгы, ТР ХЭбТИХ ДУ | Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына хисап | <br><br><br><br><br><br><br>25 кешедән артык булган | <br><br><br><br><br><br><br>90 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | тырган очракта дәүләт ярдәме чараларынннан файдалану мөмкинлеге турында мәгълүмат бирү<br><br>субсидияләү кысаларында күрсәтелгән вакансияләргә яшьләр арасыннан кандидатуралар сайлап алу | | | | эш бирүчеләр саныннан өлеш, процент<br><br>субсидияләү чаралары буенча күрсәтелгән вакансияләргә яшьләр арасыннан гражданнар эшкә урнаштырылган вакансияләр өлеше, процент | <br><br>90 |